**Республика Татарстан**
**САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**САКЛОВ-БАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ**
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклаубаш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.01.2026 № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында"23.01.2026 № 30 карары, нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 9678,63 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башкарма комитетының “Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында "2025 ел, 29 январь, 1 нче карары үз көчен югалткан дип санарга
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Саклаубаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Габидуллина Л.М.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның 30 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегендә, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган законлы вәкилгә яисә башка затка күрсәтелә торган күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе.

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4170,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1913,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3595,00 |
| Барлыгы | **9678,63** |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2026 елның 30 гыйнварындагы
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән үлгән кешенең тормыш иптәше, якын туганнары, бүтән туганнары йә законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук үлгән кешене җирләүне, җирләүне үз өстенә алган башка затлар булмаганда яисә эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнгәннән соң җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе аның шәхес эшләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 1500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2670,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1913,26 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3595,00 |
| Барлыгы | **9678,63** |